# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 6*
*июнь*
*(I өлеш)*
*2014*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
2014

**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84 1/16. Тираж 65 экз.
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2014

Эчтәлек

# I

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

562. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .............. 4

563. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................................................ 6

564. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .............. 8

565. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........11

566. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........................................................12

567. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................18

**568.** «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесендә белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме турында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............20

569. «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*...............................24

570. «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы*...............................31

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 562. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның икенче абзацында «салым ставкалары,» сүзләреннән соң «салым түләүчеләр – оешмалар тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

2) 8 статьяда:

а) исемендә «Салым түләүчеләр – оешмалар тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2003 елның 28 ноябрендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктының алтынчы – унынчы абзацларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2005, № 11);

2) «Транспорт салымы турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2005

елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 5 пунктының бишенче – җиденче абзацларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11; 2010, № 10 (II өлеш);

3) «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның 6 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4);

4) «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 21 июлендәге 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 7 (I өлеш);

5) «Транспорт салымы турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 14 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 6 пунктының «а» пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш).

2. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2014 елның 26 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3) юкка чыгарырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 2 июне
№ 42-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 563. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) квота – эш бирүче тарафыннан эшкә урнаштырылырга тиешле инвалидларны эшкә алу өчен эш бирүче хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саныннан процентларда билгеләнгән эш урыннары саны;»;

2) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. **Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм махсус эш урыннарының минималь санын билгеләү тәртибе**

1. Хезмәткәрләренең саны 100 кешедән артыграк булган эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә алу өчен квота хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан 2 дән 4 процентка кадәр күләмдә билгеләнә. Хезмәткәрләренең саны 35 кешедән ким булмаган һәм 100 кешедән артык булмаган эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә алу өчен квота хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан 3 процент күләмендә билгеләнә.

2. Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре һәм устав (җыелма) капиталы инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе кертемнәреннән торган алар оештырган оешмалар, шул исәптән

хуҗалык итү ширкәтләре һәм җәмгыятьләре булган эш бирүчеләр инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квотаны үтәүдән азат ителәләр.

3. Эш урыннарын мәҗбүри квоталаудан үзләренә карата законнарда билгеләнгән тәртиптә ябу турында карар кабул ителгән юридик затлар (оешмалар) булган эш бирүчеләр азат ителәләр.

4. Квотаны планлаштырганда, инвалидлар категориясенә кертелгән хезмәткәрләр биләп тора торган эш урыннарының саны исәпкә алына.

5. Инвалидларны эшкә алу өчен квотаны исәпләп чыгарганда хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача санына хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрү яисә хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләре буенча зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларына кертелгән хезмәт шартлары булган хезмәткәрләр кертелми.

6. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар хезмәткәрләренең исемлектәге уртача санына федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә вазыйфага сайлап кую, тиешле вазыйфаны биләүгә конкурс буенча сайлап алу, вазыйфага билгеләнү яисә вазыйфага раслану юлы белән биләнә торган вазыйфалар керми.

7. Квота, тиешле территориядә хезмәт базарындагы барлыкка килгән вәзгыятьтән чыгып, кимендә бер календарь елга билгеләнә.

8. Квота кертү турында эш бирүчеләргә ул кертелә башлаганчы кимендә ике ай алдан хәбәр ителә.

9. Эш бирүчеләргә билгеләнгән квота кысаларында инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарының минималь саны билгеләнә.

10. Квота һәм инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарының минималь саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәдән чыгып билгеләнә.»;

3) 4 статьяның 1 өлешендә «3 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалардан тыш» сүзләрен «3 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмалардан тыш» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 статьяның 2 өлешендә «3 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалардан тыш» сүзләрен «3 статьясындагы 2

һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмалардан тыш» сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «оешмада» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 9 июне
№ 43-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 564. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 6 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктында «озак сроклы максатчан» сүзләрен «дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

2) 9 статьяның 1 өлешендә «ата-аналары һәм балалары» сүзләрен «ата-аналары, балалары һәм балаларының ире яисә хатыны» сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктында «озак сроклы максатчан» сүзләрен «дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

4) 14 статьяда:

а) исемендә «һәм муниципаль» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә «һәм муниципаль» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 19 статьяның 2 өлешендә «Хисап палатасы Регламентында билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «әлеге Законга кушымта нигезендәге рәвеш буенча» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Язма хәбәрне билгеләнгән вакытта тапшыру мөмкинлеге булмаган очракта, Хисап палатасы Рәисенә мөмкин булган башка алым белән хәбәр ителә, аннан соң язмача хәбәр жибәрелә.»;

6) 26 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында «озак сроклы максатчан программалар» сүзләрен «дәүләт программалары» сүзләренә алмаштырырга;

7) 32 статьяның 6 өлешендәге 3 пунктында «хезмәткәрләренә һөнәри әзерлек, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү буенча» сүзләрен «хезмәткәрләренең һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем алуына» сүзләренә алмаштырырга.

8) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
Хисап палатасы турында»
Татарстан Республикасы
Законына кушымта

Татарстан Республикасы Хисап палатасы
Рәисенә ______________________________
______________________________________
(Рәиснең фамилиясе, инициаллары)

## Кассаларны, касса һәм хезмәт биналарын, складларны һәм архивларны мөһерләп бикләп кую, документларны һәм материалларны тартып алу турында

## ХӘБӘРНАМӘ

Сезгә ____________________________________________ карата
(тикшерелүче орган яисә оешма исеме һәм адресы)

______________________________ контроль чарасы уздырганда
(контроль чарасы исеме)
«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясындагы 2 өлеше нигезендә
__________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Хисап палатасы вазыйфаи затының
__________________________________________________________
вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)
__________________________________________________________
тарафыннан түбәндәгеләрне мөһерләп бикләп кую (тартып алу) турында хәбәр итәм:
__________________________________________________________
(мөһерләнеп бикләп куелган объектлар, алынган документлар һәм материаллар исемлеге)

Мөһерләп бикләп кую (тартып алу) вазыйфаи зат ______________
__________________________________________________________
(вазыйфасы, тикшерелүче орган яисә оешма исеме, тикшерелүче орган яисә оешманың, вазыйфаи затының фамилиясе, инициаллары)
_________________________________ катнашында башкарылды.

Объектларны мөһерләп бикләп кую (документларны һәм материалларны тартып алу) факты буенча акт (актлар) төзелде, __ биттә __ нөсхәдә күчермәсе (күчермәләре) кушымта итеп бирелә.
«______» сәг. «_____» мин.
20___ елның «____» ______ ______________________________

(Татарстан Республикасы Хисап палатасы вазыйфаи затының шәхси имзасы, фамилиясе, инициаллары)»

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 9 июне
№ 44-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 565. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 8 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2007, № 7 (I өлеш), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8) Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарлар белән элемтәне ныгыталар, аларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, үзенчәлекне саклап калуда ярдәм итәләр;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 9 июне
№ 45-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 566. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Дәүләти-хосусый партнерлык концессия килешүен, тормыш циклы контрактын төзү һәм үтәү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин;»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү (алга таба шулай ук – килешү) – гамәлдәге законнарда каралган төрле шартнамәләрнең элементлары кергән, дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары арасында төзелә һәм дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашырганда аларның хокукларын, бурычларын һәм җаваплылыгын билгели торган шартнамә. Килешү яклары мөнәсәбәтләренә карата тиешле өлешләрдә элементлары килешүгә кергән шартнамәләр турында граждан законнары кагыйдәләре кулланыла;»;

в) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Килешү гамәлдәге законнар нигезендә әйләнеше чикләнгән объектларга карата төзелә алмый;»;

2) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары**

1. Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йә Татарстан Республикасы дәүләт

хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма органы (алга таба — вәкаләтле орган), бер яктан, һәм хосусый партнер, икенче яктан, дәүләти-хосусый партнерлыкның субъектлары (килешү яклары) булалар.

2. Россиянең юридик яисә физик заты йә юридик зат төземичә генә гади ширкәт шартнамәсе (уртак эшчәнлек турында шартнамә) буенча эш итүче, эшчәнлеген килешү нигезендә гамәлгә ашыручы юридик затлар берләшмәсе хосусый партнер була ала, моңа түбәндәгеләр керми:

1) дәүләт компанияләре;

2) дәүләт корпорацияләре;

3) дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр;

4) дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр.

3. Чит илнең юридик яисә физик заты да, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, хосусый партнер була ала.

4. Әлеге статьяның 1 — 3 өлешләрендә күрсәтелгән затлар белән беррәттән муниципаль берәмлекләр исеменнән ихтыярый башлангычларда тиешле җирле үзидарә органнары, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары (килешү яклары) була ала.»;

3) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешләре**

1. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуы финанс, мөлкәт рәвешләрендә, мәгълүмати ярдәм күрсәтү рәвешендә һәм законнарга, шул исәптән «Концессия килешүләре турында» Федераль законда каралган башка рәвешләргә каршы килми торган рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта финанс рәвешендә катнашуы түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) хосусый партнерның килешүне үтәү өчен заем акчаларын җәлеп итүгә бәйле барлыкка килә торган йөкләмәләрне тиешенчә башкаруын тәэмин итүгә дәүләт гарантияләре бирү;

2) килешүне үтәгәндә алынмый калган керемнәрне каплау һәм (яисә) товарлар җитештерүгә (сатуга), эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләргә бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү (каплау) максатларында хосусый партнерга субсидияләр бирү;

3) хосусый партнерга — юридик затка бюджет инвестицияләре бирү;

4) проектлау алды һәм проектлау документларын эшләү, шулай ук килешү объектын булдыру, реконструкцияләү һәм (яисә) эксплуатацияләү чыгымнарын финанслау яисә финанслашу;

5) килешү шартлары нигезендә хосусый партнер мөлкәтен сатып алу;

6) килешүдә каралган һәм хосусый партнер җитештергән товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) билгеле күләмен җайга салына торган тарифлар (бәяләр) буенча түләү;

7) хосусый партнерның килешү объектын булдыруга яисә реконструкцияләүгә керткән акчаларын килешү шартлары нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан кире кайтаруны тәэмин итү.

3. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта мөлкәт рәвешендә катнашуы түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) җир законнары нигезендә хосусый партнерга килешү объекты урнашкан яисә төзелә торган һәм (яисә) хосусый партнерның килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыруы өчен кирәкле җир кишәрлекләре бирү;

2) хосусый партнерга Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәткә ия булу һәм аннан файдалану хокукы бирү;

3) хосусый партнерның күчемсез (күчемле) мөлкәт объектын (килешү объектын) булдыру һәм (яисә) реконструкцияләү, аны алга таба эксплуатацияләвен килешүдә билгеләнгән тәртиптә, шартларда һәм вакыт дәвамында гамәлгә ашыру максатларында хосусый партнерга Татарстан Республикасы милкендәге башка күчемсез һәм (яисә) күчемле мөлкәтне йә Татарстан Республикасының махсус хокукларын ышанычлы идарәгә, алар белән эш итүгә һәм (яисә) алардан файдалануга тапшыру, бу вакыт тәмамлангач, хосусый партнер килешү объектын Татарстан Республикасы дәүләт милкенә тапшыра.

4. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта мәгълүмати ярдәм күрсәтү рәвешендә катнашуы региональ мәгълүмат системалары һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре булдыру яисә аларны бирү һәм аларның эшләвен тәэмин итү юлы белән, шулай ук законнарда тыелмаган башка ысуллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5. Бер килешү кысаларында Татарстан Республикасы дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыруның бер яисә берничә рәвешендә катнашырга мөмкин.

6. Дәүләти-хосусый партнерлык мөнәсәбәтләрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең катнашу

рәвешләре, әлеге Закон нигезләмәләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.»;

4) түбәндәге эчтәлекле 6[1] статья өстәргә:

«6[1] статья. **Килешүнең эчтәлегенә таләпләр**

1. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта әлеге Законда каралган рәвешләрдә катнашуы килешүләрдә түбәндәге шартларны мәҗбүри килештерү шарты белән гамәлгә ашырыла:

1) килешү объектын;

2) килешү объектына милек хокукын, шул исәптән килешү якларының килешү объектына милек хокукында өлешләр бүлүне, мондый хокук барлыкка килү шартларын һәм вакытын;

3) килешүнең гамәлдә булу срогын һәм (яисә) аны билгеләү тәртибен;

4) килешү яклары арасында исәп-хисаплар ясау, шул исәптән Татарстан Республикасы милкендәге килешү объектыннан файдаланган өчен түләү тәртибен;

5) килешү яклары арасында ихтимал зыяннарны бүлү;

6) килешү якларының йөкләмәләрне үтәүләрен тәэмин итү ысулларын;

7) килешү шартларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыкны.

2. Дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган шартлардан тыш, килешүләрдә федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган теләсә кайсы башка шартларны, аерым алганда түбәндәгеләрне килештереп гамәлгә ашырыла:

1) килешү объекты Татарстан Республикасы милкенә тапшырылырга тиеш булган очракта, аның сыйфатына таләпләрне дә кертеп, килешү объектын Татарстан Республикасына тапшыру тәртибен һәм срокларын;

2) килешү объекты Татарстан Республикасы милкенә тапшырылырга тиеш булган очракта, Татарстан Республикасының килешү объектын киләчәктә кулланувы максатларында мәгълүмат, мөлкәт һәм хокукларны, шул исәптән интеллектуаль милек хокукларын тапшыру тәртибен;

3) хосусый партнерның килешү нигезендә физик һәм юридик затларга товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) тапшыруын тәэмин итүен;

4) килешү объектын Татарстан Республикасы милкенә тапшыру вакытына кадәр аны килешү шартлары нигезендә эксплуатацияләү тәртибен;

5) килешү объектын булдыру, аңа хезмәт күрсәтү, аны реконструкцияләү, модернизацияләү һәм (яисә) эксплуатацияләү эшләрен башкару срогын, шулай ук бу килешүне озайту тәртибен;

6) хосусый партнерның килешү объектын залогка, башка йөкләмә хокукларында тапшыру йә кичектереп тору шартында сату мөмкинлеген, шулай ук аның хокукларын, шул исәптән, килешүдә билгеләнгән хәлләр барлыкка килгәндә, акчалата таләп буенча финанс шартнамәсе кысаларында өстәмә килешү төзеп тормыйча күчерү мөмкинлеген;

7) хосусый партнерның килешү объектын эксплуатацияләвен туктатуны (туктатып торуны) Татарстан Республикасы белән килештерү тәртибен һәм эксплуатацияләүне туктатканда яисә килешүне өзгәндә компенсацияләү тәртибен, мондый туктату (туктатып тору) җиңә алмаслык көчләр йогынтысына бәйле очраклардан, шулай ук Россия Федерациясе законнарында һәм килешүдә каралган башка очраклардан гайре;

8) хосусый партнерга килешү буенча хокукларны һәм бурычларны, шул исәптән бурычны таләп итү һәм (яисә) күчерү таләпләренә хокукны күчерү тәртибендә тапшыруга, шулай ук килешү буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү максатларында килешү объектын залогка яисә башка хокукка тапшыруга ризалык бирү тәртибен;

9) килешүне үтәүгә бәйле зыяннарны һәм җаваплылыкны иминләштерүне;

10) килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәү өчен хосусый партнер тарафыннан җәлеп ителә торган өченче затларның килешүдә катнашуын хосусый партнерның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган белән килештерү бурычын;

11) килешү шартлары җитди бозылганда яисә килешүдә күрсәтелгән башка хәлләр барлыкка килгәндә, аерым алганда ихтимал зыянны яисә гадәттән тыш хәлләрнең куркыныч нәтиҗәләрен булдырмый калу, киметү яисә бетерү, физик һәм юридик затларның сәламәтлеген, иминлеген һәм мөлкәтләренең сакланышын, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү максатларында хосусый партнер белән килешүне өзү тәртибен;

12) финанс оешмасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган һәм (яисә) хосусый партнер арасында килешү объектына карата килешүләр төзү мөмкинлеген;

13) килешү объектына, килешү нигезендә башкарыла торган эшләргә яисә хезмәт күрсәтүләргә карата хосусый партнер ирешергә тиешле конкрет нәтиҗәләрне яисә күрсәткечләрне, аларга ирешү ысулларына бәйсез рәвештә, күрсәтү юлы белән хосусый партнерның бурычларын билгеләвен;

14) килешүне үтәү өчен хосусый партнерга бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге җир кишәрлекләре, күчемле һәм күчемсез милекнең башка объектлары, шулай ук хокуклар исемлеген;

15) килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен бирү тәртибен һәм хосусый партнер белән бу җир кишәрлекләрен арендалау (субарендалау) шартнамәләрен төзү срогын (җир кишәрлекләрен арендалау (субарендалау) шартнамәләрен төзү килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта);

16) килешү шартларын берьяклы үзгәртүнең һәм (яисә) аны үтәүдән берьяклы баш тартуның аерым очракларын;

17) федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка шартларны.

3. Җир кишәрлекләрен арендалау (субарендалау) шартнамәләре төзү килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта, җир кишәрлеген арендалау (субарендалау) шартнамәсе, конкурс документларында башка сроклар билгеләнмәгән булса, хосусый партнер белән килешү имзаланган көннән алып алтмыш эш көненнән дә соңга калмыйча төзелергә тиеш.

4. Хосусый партнер җир кишәрлеген арендалау (субарендалау) шартнамәсе буенча хокукларын, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсендә бүтәне каралмаган булса, башка затларга тапшырырга һәм җир кишәрлеген субарендага бирергә тиеш түгел.

5. Килешүне өзү хосусый партнерга җир кишәрлегенә карата бирелгән хокукларны бетерү өчен нигез булып тора.

6. Килешү объектларын эксплуатацияләгәндә гамәлгә ашырыла торган товарларга, эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә тарифларны дәүләт җайга салуы карала торган дәүләти-хосусый партнерлыкның проектларын башкарганда, килешүнең гамәлдә булу вакыты дәвамында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салу өлкәсендәге вәкаләтле органы һәм хосусый партнер арасында өчьяклы озак сроклы тариф килешүе (алга таба – тариф килешүе) төзелергә мөмкин. Тариф килешүендә хосусый партнерның килешү объектын эксплуатацияләве чорына бәяләр (тарифлар, аларга өстәмәләр) билгеләү һәм кую тәртибе, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салу өлкәсендәге вәкаләтле органы әзерли һәм раслый торган озак сроклы тариф сценарие, шулай ук, озак вакытлы тариф сценариенда каралган диапазон чикләреннән чыга торган тарифлар билгеләнгән очракта, хосусый партнерга компенсацияләр бирү механизмы каралырга тиеш.»;

5) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы исеменнән концессия килешүләре «Концессия килешүләре турында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган тарафыннан төзелә.»;

6) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Коллегиаль киңәшү органы**

Дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү, килешүләрне гамәлгә ашыруны һәм Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән башка мәсьәләләрне хәл итүне мониторинглауны Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасында инвестиция климатын яхшырту буенча коллегиаль киңәшү органы башкара.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 9 июне
№ 46-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 567. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма бас-

масы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (1 өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2; Ватаным Татарстан, 2014, 17 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «ике йөздән алып биш йөз сумга кадәр» сүзләрен «бер меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләренә, «ике меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләрен «биш меңнән алып ун мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «бер меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләрен «өч меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләренә, «йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр» сүзләрен «йөз илле меңнән алып ике йөз мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешнең икенче абзацында «бер меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләрен «өч меңнән алып дүрт мең сумга кадәр» сүзләренә, «биш меңнән алып ун мең сумга кадәр» сүзләрен «ун меңнән алып унбиш мең сумга кадәр» сүзләренә, «алтмыш меңнән алып йөз мең сумга кадәр» сүзләрен «йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлешнең икенче абзацында «өч меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләрен «дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләренә, «йөз илле меңнән алып ике йөз мең сумга кадәр» сүзләрен «ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4.3 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләрен «кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «бер меңнән алып бер мең биш йөз сумга кадәр» сүзләрен «өч меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләренә, «ике меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләрен «егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр» сүзләренә, «егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр» сүзләрен «ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4.4 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләрен «кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «бер меңнән алып бер мең биш йөз сумга кадәр» сүзләрен «өч меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләренә, «ике меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләрен «егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр» сүзләренә, «егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр» сүзләрен «ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 9 июне
№ 47-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 568. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесендә белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Татарстан Республикасы территориясендә фәнни-тикшеренү һәм инновация эшчәнлеген камил, тотрыклы һәм нисбәтле үстерүгә ярдәм итү; икътисадның төрле тармакларында һәм социаль өлкәдә гамәли әһәмияткә ия яңа фәнни мәктәпләр булдыру нигезендә Татарстан Республикасында заманча мәгариф системасын төзү; Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенә Россиянең һәм чит илләрнең әйдәп баручы фән-мәгариф үзәкләренең һәм корпорацияләренең алдынгы тәҗрибәсен кертү; Татарстан Республикасын социаль-икътисадый һәм социаль-мәдәни үстерү өлкәсендә программалар һәм проектлар эшләү һәм аларны фәнни яктан тәэмин итү максатларында, әлеге Законда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесендә (алга таба – Университет) белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре;

2) Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Университетның үзара эшчәнлегенең төп юнәлешләре.

**2 статья. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүнең хокукый нигезе**

Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүнең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Төньяк-Көнбатыш, Идел буе, Урал һәм Ерак Көнчыгыш федераль округларында федераль университетлар төзү турында» Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 октябрендәге 1172 номерлы Указы, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 13 сентябрендәге 1543-р номерлы күрсәтмәсе белән хупланган 2010 – 2019 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесен үстерү программасы, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары тәшкил итә.

**3 статья. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәмен, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, экологик, демографик, этномәдәни һәм башка региональ үзенчәлекләрен исәпкә алып, Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын законнарда билгеләнгән тәртиптә эшләү һәм тормышка ашыру юлы белән Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы законнары кабул итү, аларның үтәлешен Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм рәвешләрдә тикшереп тору;

2) Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджеты составында раслау;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Университетка түләүсез куллануга тапшыру турында карарлар кабул итү;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын үз компетенциясе чикләрендә эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме буенча вәкаләтләрен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә гамәлгә ашыра.

4 статья. **Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасы**

Татарстан Республикасы дәүләт программасы Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган программалар һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актлары кысаларында Университетны үстерүнең төп юнәлешләре нигезендә Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын билгели.

5 статья. **Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Университетның үзара эшчәнлегенең төп юнәлешләре**

Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Университетның үзара эшчәнлеге түбәндәге төп юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

1) белем бирү процессын белем бирүнең яңа төрләрен, программаларын һәм стандартларын эшләү, белем бирүнең яңа технологияләрен һәм уку-укытуга ярдәм итү системаларын кертү юлы белән модернизацияләү;

2) фәнни-тикшеренү процессын модернизацияләү;

3) Университетның кадрлар потенциалын үстерү, шул исәптән фәнни-педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсешенә ярдәм итү һәм аны стимуллаштыру, кадрларны яңарту, Россия һәм чит илләр укытучыларын, тикшеренүчеләрен һәм практикларын җәлеп итү;

4) Университет инфраструктурасын модернизацияләү;

5) Университетны глобаль фәнни-мәгариф һәм инновация челтәрләренә тоташтыру һәм төбәк дәрәҗәсендә аларның формалашуына ярдәм итү;

6) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре кысаларында башка юнәлешләр.

6 статья. **Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәмен финанс белән тәэмин итү**

1. Университетта белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләме Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

7 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 9 июне
№ 48-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 569. «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2013 елның 30 ноябрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктта «33 560 869,8» саннарын «33 578 958,1» саннарына, «7 755 061,2» саннарын «7 764 672,8» саннарына алмаштырырга;

б) 2 пунктта «34 997502,8» саннарын «35 371 543,8» саннарына алмаштырырга;

в) 3 пунктта «1 436 633,0» саннарын «1 792 585,7» саннарына алмаштырырга;

2) 7 статьяның 1 өлешендә «2 266 118,7» саннарын «2 267 524,5» саннарына алмаштырырга;

3) 1 нче кушымтада:

| | | |
|---|---|---|
| «000 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 1 436 633,0 |
| 000 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү | 1 436 633,0 |
| 395 01 05 02 01 09 0000 510 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының калган башка акчалата чараларын арттыру | |

| | | |
|---|---|---|
| 395 01 05 02 01 09 0000 610 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының калган башка акчалата чараларын киметү | 1 436 633,0» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «000 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 1 792 585,7 |
| 000 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү | 1 792 585,7 |
| 395 01 05 02 01 09 0000 510 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының калган башка акчалата чараларын арттыру | |
| 395 01 05 02 01 09 0000 610 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының калган башка акчалата чараларын киметү | 1 792 585,7»; |

4) 3 нче кушымтада:

а)

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 05812 09 0000 151 | Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен башкаруга территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 05812 09 0000 151 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминләштерүен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр»; |

б)

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 09029 09 0000 151 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 08 09000 09 0000 180 | Артык түләнгән яисә артык түләттерелгән салымнар, җыемнар һәм бүтән түләүләрне кайтару, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык түләттерелгән суммаларга процентларны кире кайтару (исәпкә алу) өчен территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларыннан (территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына) акча күчерүләр»; |

5) 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

## 2014 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 000 1 00 00000 00 0000 000 | Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 190 036,4 |
| 395 1 11 00000 00 0000 000 | Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 8 476,7 |
| 395 1 11 02000 00 0000 120 | Бюджетлар акчаларын урнаштырудан керемнәр | 8 476,7 |
| 395 1 11 02072 09 0000 120 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларының вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан керемнәр | 8 476,7 |
| 395 1 17 00000 00 0000 000 | Салым булмаган башка керемнәр | 181 559,7 |
| 395 1 17 06000 00 0000 180 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына салым булмаган башка кертемнәр | 181 559,7 |
| 395 1 17 06040 09 0000 180 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына салым булмаган башка кертемнәр | 181 559,7 |
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 33 388 921,7 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган кертемнәр | 33 388 921,7 |
| 395 2 02 05000 00 0000 151 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 28 070 269,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 02 05202 09 0000 151 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы өлешендә гамәлгә ашыруны өстәмә финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 2 267 637,1 |
| 395 2 02 05203 09 0000 151 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасында билгеләнмәгән өстәмә медицина ярдәме күрсәтү төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 178 383,0 |
| 395 2 02 05800 09 0000 151 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды акчалары | 25 624 248,9 |
| 395 2 02 05812 09 0000 151 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминләштерүне оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 25 624 248,9 |
| 395 2 02 09000 00 0000 151 | Бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 5 318 652,7 |
| 395 2 02 09029 09 0000 151 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 5 318 652,7 |
| | Керемнәр, барлыгы | 33 578 958,1»; |

6) 7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар планчорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 7 нче кушымта

## 2014 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 185 352,3 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 185 352,3 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару | 395 | 01 | 13 | 73 2 0000 | | 185 352,3 |
| Дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген (хезмәт күрсәтүләрен) тәэмин итүгә чыгымнар | 395 | 01 | 13 | 73 2 0059 | | 185 352,3 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләүләргә чыгымнар | 395 | 01 | 13 | 73 2 0059 | 100 | 122 114,2 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 0059 | 200 | 60 070,3 |
| Бүтән бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 0059 | 800 | 3 167,8 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 35 094 469,8 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 22 000,0 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 73 1 3300 | | 22 000,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 73 1 3300 | 300 | 22 000,0 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 35 072 469,8 |
| Социаль сәясәт өлкәсендә дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 73 1 0000 | | 35 072 469,8 |
| Медицина ярдәменең югары технологияле төрләре | 395 | 09 | 09 | 73 1 0200 | | 1 653 802,6 |
| Югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү | 395 | 09 | 09 | 73 1 0202 | | 1 653 802,6 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 73 1 0202 | 300 | 1 653 802,6 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары эшчәнлегенең программада билгеләнмәгән юнәлешләре буенча социаль сәясәт өлкәсендә дәүләт функцияләрен гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминләштерүен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 395 | 09 | 09 | 73 1 5093 | | 29 689 155,8 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 73 1 5093 | 300 | 29 689 155,8 |
| Бер каналлы финанслау кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы чараларын гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 73 1 1706 | | 178 383,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 73 1 1706 | 300 | 178 383,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 73 1 3300 | | 3 551 128,4 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 09 | 73 1 3300 | 300 | 3 551 128,4 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 91 721,7 |
| Халыкны социаль тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | | | 91 721,7 |
| Социаль ярдәм | 395 | 10 | 03 | 50 5 0000 | | 91 721,7 |
| Хезмәт ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 50 5 5520 | | 90 150,0 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 50 5 5521 | | 89 825,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 50 5 5521 | 300 | 89 825,0 |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 50 5 5522 | | 325,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 50 5 5522 | 300 | 325,0 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга со-циаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 50 5 5530 | | 964,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 50 5 5532 | 300 | 964,1 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 50 5 8501 | | 607,6 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 10 | 03 | 50 5 8501 | 300 | 607,6 |
| Барлык чыгымнар | 395 | | | | | 35 371 543,8». |

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 9 июне
№ 49-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 570. «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 94-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә:
а) 1 пунктта «142 172 188,0» саннарын «150 884 866,6» саннарына алмаштырырга;
б) 2 пунктта «151 787 073,4» саннарын «162 844 896,2» саннарына алмаштырырга;
в) 3 пунктта «9 614 885,4» саннарын «11 960 029,6» саннарына алмаштырырга;

2) 2 статьяда:
а) 4 өлешнең икенче абзацында «87 448 667,4» саннарын «97 448 667,4» саннарына алмаштырырга;
б) 5 өлештә «2015 һәм 2016 еллар план чорына» сүзләре алдыннан «2014 елга Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулар программасын һәм» сүзләрен өстәргә;
в) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:
